«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы

КАРАРЫ

2024елның 16 августы №106

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Җир салымы турында» 2017 елның 14 декабрендәге 69 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 387 статьясындагы 2 пункты, шулай ук «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 36 статьясы нигезендә КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 статьяның беренче өлешенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«- җирле үзидарә органнары, су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү объектлары, гомуми файдаланудагы мәйданнар, урамнар, юллар, парклар, аллеялар, яшел утыртмалар, истәлекләр, бәйрәм чараларын үткәрү урыннары, спорт объектлары һәм гомуми файдаланудагы башка объектлар биләгән җир кишәрлекләренә карата җирле бюджеттан финанслана торган бюджет, казна учреждениеләре.».

2. Әлеге карарның 3 статьясындагы 5 абзацы үз көчен 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырырга, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

“Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге”
муниципаль берәмлеге башлыгы , Совет рәисе И.А.Зиновьев